**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«______» _____________ 20_____ел № _________

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 26 июленнән №86-17 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Гавами тыңлауларны билгеләргә:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2022 елның 26 июлендәге 86-17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча:

1.2 Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- түбәндәге кадастр номерлары булган җир участокларының территориаль зонасын 16:02:070201:511, 16:02:070201:790, 16:02:070201:481 индивидуаль торак төзелеше зонасына (Ж1) га үзгәртергә.

1.3. Шәһәр төзелеше регламентларында:

- Шәхси торак төзелеше зоналарының (Ж1), аз катлы торак төзелешле зоналарның (Ж2), урта катлы торак төзелешле зоналарның (Ж3) шәһәр төзелеше регламентларын «Үз ихтыяҗлары өчен гаражлар урнаштыру» куллануның шартлы рөхсәт ителгән төре белән тулыландырырга (код 2.7.2).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Азнакай муниципаль районының "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлегенең

җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне ачык тыңлауларны оештыручы;

- үткәрү вакыты - 2023 елның 25 июленнән 2023 елның 14 августына кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрелү урыны - Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт;

2023 елның 14 маена кадәр тикшерелә торган мәсъәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адрес - Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев ур., 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге (эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр)

3. «Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проектын әзерләү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытларда гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Азнакай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты материалларын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин